ГЛАВА НИЖНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ТҮБӘН ОСЛАН
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Нижний Услон _______________

1 12.01

Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга сала торган законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 43 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актларын регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле муниципаль районга керүче җирлекләрдән мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башлыгы белән төзелгән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җибәрү мәсьәләләре буенча үзара ярдәм итешү турында килешү нигезендә

карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башлыгының 2016 елның 11 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җыю һәм җибәрү буенча Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый

актлар һәм алар турында белешмәләр җибәрү барышында Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге Регламентына таянырга тәкъдим итәргә;

2. Җирлек Советының муниципаль норматив хокукый актларын, җирлек башлыгын һәм башкарма комитетын, шулай ук алар турында белешмәләр, регистрга кертелергә тиешле белешмәләрне җибәрү өчен җаваплы, җирлек башкарма комитеты секретарен билгеләргә.

3. Карарны Югары Ослан районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районының
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.З.Шайдуллин